БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«_29_» __05___ 2020 г. № _188_

**Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карамагындагы оешмаларда хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормалары булган башка норматив хокукый актлар үтәлешенә ведомство контролен гамәлгә ашыру турында**

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 353.1 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормалары булган башка норматив хокукый актларның үтәлешенә ведомство контроле турында» 2019 елның 14 декабрендәге 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карамагындагы оешмаларда хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормалары булган башка норматив хокукый актлар үтәлешенә ведомство контролен гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карамагындагы оешмаларда хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормалары булган башка норматив хокукый актлар үтәлешенә ведомство контролен гамәлгә ашыру буенча эшче төркем төзергә һәм әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә эшче төркем составын расларга.

2. Әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карамагындагы оешмаларда хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормалары булган башка норматив хокукый актлар үтәлешенә эшче төркем тарафыннан ведомство контролен гамәлгә ашыру тәртибе турында Нигезләмәне расларга.

3. Әлеге карарның 3 нче кушымтасы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карамагындагы оешмаларда хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормалары булган башка норматив хокукый актлар үтәлешенә 2020 елга планлы тикшерүләр үткәрү планын расларга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А.Ф. Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2020 елның _29 маеннан__________
188  номерлы карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карамагындагы оешмаларда хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормалары булган башка норматив хокукый актлар үтәлешенә ведомство контролен гамәлгә ашыру буенча эшче төркем составы

| | | |
|---|---|---|
| Эшче төркем җитәкчесе | Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары | Галимуллин Илшат Солтан улы |
| Эшче төркем җитәкчесе урынбасары | Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының гомуми-оештыру бүлеге башлыгы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы профсоюз оешмаларының координация советы рәисе | Нургалиев Рамил Камил улы |
| Эшче төркем секретаре | Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе ярдәмчесе | Һадиев Булат Харис улы |
| Эшче төркем әгъзалары: | Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының икътисад һәм фаразлау бүлеге башлыгы | Галимҗанов Фәнис Фәргать улы |
| | Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының юридик бүлек башлыгы | Фатыйхов Ренат Сабит улы |

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2020 елның 29 маеннан___________
188  номерлы карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карамагындагы оешмаларда хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормалары булган башка норматив хокукый актлар үтәлешенә эшче төркем тарафыннан ведомство контролен гамәлгә ашыру тәртибе турында
НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмә

1.1. Әлеге нигезләмә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карамагындагы оешмаларда хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормалары булган башка норматив хокукый актлар үтәлешенә ведомство контролен (алга таба – ведомство контроле) гамәлгә ашыру буенча эшче төркемнең эш тәртибен билгели.
1.2. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет)карамагындагы оешмаларда хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормалары булган башка норматив хокукый актлар үтәлешенә ведомство контроле эшче төркем (алга таба – эшче төркем) тарафыннан башкарыла.
1.3. Эшче төркем оештыручысы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Башкарма комитет гамәлгә ашыручы оешмаларга (алга таба - ведомствога караган оешма) карата ведомство контролен гамәлгә ашыра.
1.4. Эшче төркем эшчәнлегенең төп формасы булып планлы һәм планнан тыш, урынга барып һәм документлар буенча тикшерүләр үткәрү тора.
1.5. Эшче төркем Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары һәм хокукый актлары, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль хокукый актлары белән билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда ведомство контролен гамәлгә ашыра.

## 2. Ведомство контроленең төп бурычлары һәм функцияләре

2.1. Ведомство контроленең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:
- хезмәт законнарын һәм хезмәт хокукы нормалары булган башка норматив хокукый актларны (алга таба - хезмәт законнарын) бозуларны ачыклау;
- хезмәткәрләрнең һәм эш бирүченең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуларны кисәтү;

- ведомство карамагындагы оешмалар хезмәткәрләренең бозылган хокукларын торгызу буенча чаралар күрү;
- җитештерүдә имгәнүләрне һәм һөнәри авыруларны кисәтү буенча профилактика эшен оештыруны, хезмәтне саклау таләпләре нигезендә шәхси һәм коллектив саклау чаралары белән тәэмин итүне, шулай ук хезмәт шартларын яхшырту эшләрен оештыруны контрольдә тоту.

2.2. Ведомство контролен тормышка ашырганда эшче төркем түбәндәге функцияләрне башкара:
- еллык тикшерүләр планын формалаштыра һәм аны Башкарма комитет җитәкчесенә «Татарстан Республикасында хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормалары булган башка норматив хокукый актлар үтәлешенә ведомство контроле турында» 2019 елның 14 декабрендәге 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 100-ТРЗ номерлы Закон) белән каралган вакытта раслау өчен җибәрә;
- тикшерү планы расланганнан соң ун көн эчендә аны Балтач муниципаль районы сайтына урнаштыру өчен җибәрә.
- 100-ТРЗ номерлы Закон нигезендә түбәндәге юнәлешләр буенча документлар буенча һәм урынга барып тикшерүне гамәлгә ашыра:

1) хезмәт шартнамәләре;
2) эш вакыты һәм ял вакыты;
3) хезмәт өчен түләү һәм хезмәтне нормалаштыру;
4) хезмәткәрләргә бирелә торган гарантияләрне һәм компенсацияләрне үтәү;
5) хезмәт тәртибе һәм хезмәт дисциплинасы;
7) хезмәткәрләрнең һөнәри әзерлеге, аларны яңадан әзерләү һәм квалификацияләрен күтәрү;
8) хезмәтне саклау;
9) хезмәт килешүе якларының матди җаваплылыгы;
10) аерым категория хезмәткәрләрнең хезмәтен җайга салу үзенчәлекләре;
11) индивидуаль һәм күмәк хезмәт бәхәсләрен карау һәм хәл итү;
12) хезмәткәрләрне аттестацияләү.

- тикшерү нәтиҗәләре буенча законнарда каралган гамәлләрне гамәлгә ашыра.

## 3. Эшче төркем составы

3.1. Эшче төркем составына кимендә биш кеше - җитәкче, җитәкче урынбасары, секретарь, эшче төркем әгъзалары керә;

3.2. Эшче төркем җитәкчесе эшче төркем эшчәнлегенә гомуми җитәкчелекне гамәлгә ашыра һәм ведомствога караган оешманың эш режимы кысаларында, тикшерү уздыру вакыты дәвамында, ведомствога караган оешманың бинасында һәм башка бүлмәләрендә эшче төркемнең көн саен булу вакытын билгели;

3.3. Эшче төркем җитәкчесе булмаганда аның вәкаләтләрен эшче төркем җитәкчесе урынбасары башкара.

3.4. Эшче төркем секретаре тикшерү нәтиҗәләре буенча документларны рәсмиләштерүне һәм эшче төркем җитәкчесенең тикшерү белән бәйле башка йөкләмәләрен гамәлгә ашыра.
3.5. Тикшерүне үткәрүгә экспертлар, эксперт оешмалары вәкилләре җәлеп ителә ала.

## 4. Эшче төркемнең хокуклары һәм бурычлары

4.1. Ведомство тикшерүен башкарганда эшче төркем түбәндәгеләргә хокуклы:
- тикшерү өчен кирәкле документларны соратып алырга;
- тикшерелә торган оешманың биналарына һәм башка бүлмәләренә керергә;
- кирәк булганда, ведомство карамагындагы оешманың техник чараларын кулланырга;
- махсус экспертизалар һәм (яки) тикшеренүләр үткәрүгә бәйле аерым очракларда, урынга чыгып тикшерү вакытын егерме эш көненнән дә артык булмаган вакытка озайту турында Башкарма комитетка дәлилләнгән тәкъдим чыгарырга.
4.2. Тикшерү уздырганда эшче төркем түбәндәгеләргә хокуклы түгел:
- тикшерү предметына карамаган таләпләрнең үтәлешен тикшерергә;
- тикшерү предметына карамаган документларны, мәгълүматны бирүне таләп итәргә;
- тикшерү нәтиҗәсендә алынган һәм дәүләт, коммерция, хезмәт серен яки закон тарафыннан саклана торган башка серне тәшкил итүче мәгълүматны, федераль законнарда каралган очраклардан тыш, таратырга;
- тикшерүләр үткәрүнең билгеләнгән вакытын арттырыга;
- ведомство карамагындагы оешманың җитәкчесе яки башка вәкаләтле вәкиле булмаган очракта тикшерү үткәрергә.

## 5. Ведомство контролен гамәлгә ашыру нәтиҗәләрен рәсмиләштерү

5.1. Тикшерү акты (1 нче кушымта) аны тәмамланганнан соң ук ике нөсхәдә рәсмиләштерелә һәм эшче төркем җитәкчесе тарафыннан имзалана, шуларның берсе кушымталарның күчермәләре белән ведомство карамагындагы оешма вәкиленә кул куйдырып тапшырыла.
5.2. Тикшерү актына җитештерү тирәлеге объектларын тикшерү беркетмәләре, үткәрелгән тикшеренүләр, сынаулар һәм экспертизалар протоколлары яки бәяләмәләре, ведомство карамагындагы оешма хезмәткәрләренең хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормалары булган башка норматив хокукый актлар таләпләрен бозган өчен җаваплылык йөкләнә торган аңлатмалары һәм тикшерү нәтиҗәләренә бәйле башка документлар яисә аларның күчермәләре теркәлә.
5.3. Дәүләт, коммерция, хезмәт серен, закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче мәгълүматны үз эченә алган тикшерү нәтиҗәләре Россия Федерациясе законнарында каралган таләпләрне үтәп рәсмиләштерелә.

5.4. Хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормалары булган башка норматив-хокукый актлар таләпләрен бозу очраклары ачыкланган очракта, аларны бетерү вакыты эшче төркемнең тикшерү актында күрсәтелә.
5.5. Ведомствога караган оешма җитәкчесе яки ведомствога караган оешманың башка вәкаләтле вәкиле билгеләнгән вакытта хезмәт законнарын һәм хезмәт хокукы нормалары булган башка норматив хокукый актларны бозуларны бетерүне тәэмин итәргә бурычлы.
5.6. Ачыкланган хокук бозуларны бетерү һәм аларны алдагы эшчәнлектә кисәтү буенча күрелгән чаралар турындагы хисап ведомство карамагындагы оешма тарафыннан Башкарма комитетка ачыкланган хокук бозуларны бетерү вакыты тәмамланган көннән алып биш көннән дә соңга калмыйча тапшырыла. Әлеге хисапка хокук бозуларны бетерүне раслый торган документларның һәм материалларның күчермәләре кушып бирелә. Тиешенчә Башкарма комитет ачыкланган хокук бозуларны бетерүне контрольдә тоту буенча чаралар күрергә тиеш.

## 6. Йомгаклау нигезләмәләре

6.1. Эшче төркем эшчәнлеге нәтиҗәсендә барлыкка килгән документлар һәм тикшерүләр материаллары Башкарма комитетта формалаша һәм саклана.
6.2. Әлеге нигезләмәнең 6.1 пунктта күрсәтелгән документларның саклanышы өчен эшче төркем җитәкчесе җаваплы.

Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карамагындагы оешмаларда хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормалары булган башка норматив хокукый актлар үтәлешенә эшче төркем тарафыннан ведомство контролен гамәлгә ашыру тәртибе турында Нигезләмәгә
1 нче кушымта

РАСЛЫЙМ

___________________________________
(вәкаләтле орган җитәкчесе вазыйфасының атамасы)

____________________ И. А. Фамилиясе
(имза)

____________________________
(дата)

**ТИКШЕРҮ АКТЫ №**
**хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормалары булган башка норматив хокукый актлар таләпләрен үтәү**

_______________________________________________________
(вәкаләтле орган исеме)

____________________ «__» ______________ 20__ ел
(актны төзү урыны) (актны төзү датасы)

______________________
(акт төзү вакыты)

Тикшерү төре, формасы:

________________________________________________________________________
(планлы яки планнан тыш, документлар буенча яки урынга чыгып тикшерү)

Тикшерү үткәрүнең нигезләре:

________________________________________________________________________
(аның нигезендә тикшерү үткәрелә торган күрсәтмәнең датасы һәм номеры)

Тикшерү түбәндәге составтагы эшче төркем тарафыннан үткәрелде:

| **№ т/б** | **Ведомство эшче төркеме әгъзасының Ф. И.А.** | **Вазифасы** |
|---|---|---|
| 1 | | |
| 2 | | |

Ведомство карамагындагы тикшерелә торган оешманың исеме:

________________________________________________________________________
(тикшерү үткән муниципаль унитар предприятие яки муниципаль учреждение исеме)

Тикшерү барышында катнашты:

______________________________________________________________________

(тикшерү үткәргәндә катнашкан ведомство карамагындагы оешма җитәкчесе яисә аның вазыйфаи затының фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм вазыйфасы)

Тикшерү үткәрелде:

______________________________________________________________________

(тикшерү үткәрү датасы, вакыты, дәвамлылыгы һәм урыны)

Тикшерү үткәрү максатыннан ведомство карамагындагы оешма тарафыннан түбәндәге документлар тапшырылды:

| № т/б | Тикшерү барышында ведомство карамагындагы оешма тарафыннан тапшырылган документлар исемлеге (исеме, датасы, номеры) |
|---|---|
| 1 | |
| 3 | |
| … | |

**Тикшерү нәтиҗәләре турында белешмәләр**

Тикшерү нәтиҗәсендә:
1) хезмәт законнарын бозу очраклары ачыкланмады;
2) түбәндәге хезмәт законнарын бозу очраклары ачыкланды (тиешле норматив хокукый актларга сылтама белән):

| № т/б | Ачыкланган хезмәт законнарын бозу очраклары | Нигезләре (НХАның пункты, статьясы, реквизитлары) |
|---|---|---|
| 1 | | |
| 2 | | |
| … | | |

Хезмәт законнарын бозуга ведомство карамагындагы оешманың түбәндәге вазыйфаи затлары тарафыннан юл куелган:

| № т/б | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Вазифасы |
|---|---|---|
| 1 | | |
| 2 | | |
| … | | |

Әлеге актта күрсәтелгән хезмәт законнарын бозу ________________________

(ачыкланган хокук бозуларны бетерү өчен) кадәр

бетерелергә тиеш.

Тикшерү үткәргән эшче төркем тарафыннан ведомство карамагындагы оешмага карата түбәндәге чараларны күрү тәкъдим ителә:

| № т/б | **Вәкаләтле органның җавап бирү чаралары** | **Ведомство эшче төркеменең тәкъдимнәре** |
|---|---|---|
| 1 | Гаепле затларны җаваплылыкка тарту турында ведомствога караган оешмага тәкъдимнәр җибәрергә | |
| 2 | Федераль законнар нигезендә ведомство карамагындагы оешма җитәкчесенә карата чаралар күрергә | |
| 3 | Ачыкланган хокук бозуларны бетерү вакыты тәмамланган көннән соң 3 эш көне эчендә ачыкланган бозулар турында мәгълүматны . ……җибәрергә. | |
| 4 | Башка чаралар (санап чыгарга) | |

Тикшерү үткәргән эшче төркем әгъзаларының имзалары:

_______________________________ /_____________________________________________/

_______________________________ /______________________________________________/

_______________________________ /______________________________________________/

Әлеге актка кушып бирелә:

_____________________________________________________________

(тикшерү нәтиҗәләренә бәйле документлар яки аларның күчермәләре исемлеге)

Тикшерү акты белән таныштым:

_________________________________________________________________

(ведомство карамагындагы оешма җитәкчесе яисә аның вәкаләтле затының фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфасы, тикшерү акты белән танышу яки тикшерү акты белән танышудан баш тарту факты)

«__» ____________20__ ел ________________

(имза)

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2020 елның _29 маеннан____________
188_ номерлы карарына
3 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карамагындагы оешмаларда хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормалары булган башка норматив хокукый актлар үтәлешенә 2020 елга планлы тикшерүләр үткәрү**
**ПЛАНЫ**

**Тикшерүләрне үткәрү максаты:** Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карамагындагы оешмаларда хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормалары булган башка норматив хокукый актлар үтәлешенә ведомство контроле.

| № т/б | Ведомство карамагындагы оешманың исеме | Ведомство карамагындагы оешманың урнашу урыны | Тикшерү формасы (документлар буенча яки урынга барып) | Планлы тикшерү үткәрү чоры | Тикшерү үткәрү вакыты |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесе «Балтач урта гомуми белем мәктәбе» | Татарстан Республикасы, Балтач районы, Балтач ш.т.п., К. Маркс урамы, 7 нче йорт | документлар буенча | октябрь | 20 эш көне |
| 2 | Балтач муниципаль районының «Катнаш төрдәге Балтач 1 нче номерлы балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе Татарстан Республикасы | Татарстан Республикасы, Балтач районы, Балтач ш.т.п., Нариман урамы, 24 нче йорт | урынга барып | ноябрь | 20 эш көне |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 3 | Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе | Татарстан Республикасы, Балтач районы, Балтач ш.т.п., Нариман урамы, 123 нче йорт | документлар буенча | декабрь | 20 эш көне |